ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

6 февраль, 2020 ел № 36/8

Шәһәр Советының 2008 елның 18 апрелендәге «Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт турында» 31/13 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28, 48, 49 статьялары нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2008 елның 18 апрелендәге «Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт турында» 31/13 санлы Карарына (Шәһәр Советының 2009 елның 9 апрелендәге 40/23, 2012 елның 20 сентябрендәге 21/11, 2013 елның 29 августындагы 26/15, 2015 елның 22 октябрендәге 2/19, 2016 елның 15 декабрендәге 13/11, 2018 елның 10 августындагы 26/14, 2019 елның 7 октябрендәге 33/14 номерлы Карарлары редакциясендә) 7.2 пунктны яңа рекдакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«7.2.Муниципаль хезмәтнең вазыйфаи бурычларына «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында» 2015 елның 25 апрелендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә катнашу йөкләнгәндә, муниципаль хезмәтнең өлкән һәм кече вазыйфаларына һөнәри белем дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләре Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә күрсәтелә.»

2. Әлеге Карар 2019 елның 1 гыйнварыннан соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советыныңң регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев